***Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе***



# Чишмә башы

***Февраль, 2025 ел***

***№ 4***



***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***

1 нче февраль көнне Наласа авыл җирлеге һәм «Игенче» агрофирмасы хисап җыелышы узды. Җыелышта Татарстан Республикасы Арча муниципаль район башлыгы Ильшат Габделфәрт улы Нуриев катнашты. Актлар залында оешмалар эшчәнлеге белән дә таныштты.

Безнең Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге «Балачак» балалар бакчасы үзенең эшчәнлеген патриотик тәрбия бирү юнәлеше буенча күрсәтте. Патриотик тәрбия бирү төшенчәсе киң мәгънәне анлата. Ул бала күңелендә табигатенә, туган йортына, туган авылына, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уятудан гыйбарәт. 2025 нче ел – Ватанны саклаучылар елы уңаеннан бакчада нинди эшләр башкарылуы, алга таба нинди максатлар куелу турында әйтелеп үтелде.





## Балаларның, тәрбиячеләрнең уңышлары


























**Туган телем-иркә гөлем»**

Туган тел! Нинди гүзәл, матур, йомшак, бөек сүз! Һәр милләтнең үз туган теле була: марыйларныкы – марый, чуашларныкы – чуаш, башкортларныкы – башкорт. Ә безнең туган телебез – татар теле! Әйе, татар теле: җырдай моңлы, кызлар кебек шат чырайлы, ачык йөзле татар теле. Ул бик борынгы һәм бай телләрнең берсе, шуңа күрә без аның белән горурланып яшәргә тиешбез. Туган тел турында берсеннән-берсе матур шигырьләр, җырлар, мәкальләр бар.

Туган тел – иң татлы тел,

Туган тел – иң тәмле тел,

Тәмле дип: телең йотма!

Туган телне онытма!

Туган тел – һәркем өчен кадерле булган бөек хәзинә. Шушы уңайдан бакчабызда туган тел атналыгы үткәрдек. Атнаның һәр көнендә төрле-төрле чаралар оештырылды.Зурлар төркеме нәниләргә «Тегүче куян» әкиятен сәхнәләштереп күрсәттеләр, татар халкының милли уеннарын яратып уйнадылар,дәү әнидә кунакта булдылар.Татар халкының милли ризыклары белән таныштылар, дәү әнинең сандыгында нәрсәләр бар икән, балалар бик кызыксынып шуны барладылар. Атна ахырында «Туган телем-иркә гөлем» исеме астында бәйрәм кичәсе үткәрдек













**«Театр - яктылыкка , нурга илтә»**

Сәләтле балаларны ачыклау, аларны иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү максатыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы тарафыннан ел 1саен балалар һәм яшүсмерләр театрларының «Сәйяр»республика фестивале уздырыла. Безнен Наласа б алалар бакчасы «Балачак» театр коллективы да бу фестивальдә актив катнаша. Быел балалар белән М.Ю. Картушинаның «Тегүче куян» экияте буенча музыкаль спектаклен тәкьдим иттек. Театр сәнгате балаларны сихри дөньяга алып керә, аларның иҗади фикерләү сәләтен ачарга ярдәм итә, сөйләм телен үстерә, эстетик һәм әхлакый тәрбия бирә. «Туган тел атналыгы» кысаларында кечкенәләр төркеме өчен, зурлар әлеге спектакльне сәхнәләштереп күрсәттеләр, нәниләр тын да алмыйча карады, аларга бик ошады.







**« Герой-шагыйрь Муса Җәлил»**

Наласа авыл китапханәсендә Гөлчәчәк Сабирҗанова белән берлектә «Герой-шагыйрь Муса Җәлил» , дип аталган патриотик сәгать үтте. Балалар белән М.Җәлилнең батырлыгы турында сөйләштек һәм аның шигырьләрен укыдык. Аның шигъри таланты, сугышчан батырлыгы һәм хәрби оештыру осталыгы бөтен тулылыгы белән ачылды. Аның балалар өчен язылган «Карак песи» шигырен укыганда бармак уеннары ярдәмендә күрсәтеп катнаштык , «Сәгать», «Әтәч» җырларын башкардык. Балаларга бик ошады. Гөлчәчәк апалары матур,эчтәлекле итеп оештырды. Муса Җәлил иҗатына соклану тудырды.





**«Безнең Әфганчылар»**


















*Ачы бураннарда*
*Куе томаннарда*
*Давылларда җилкән кебек без!*
*Җиһаннан нур алган,*
*Нигезләрдә калган,*
*Милләт өчен янган егет без...*
*Авылда чыныккан*
*Көлмәгән сыныктан,*
*Тормыш арбасында дегет без!*
*Дөньяны агарткан,*
*Үз илен яраткан,*
*Яшим , дип җан аткан егет без*

*Рүзәл Минһаҗев*

Наласа балалар бакчасында, үзләрен чын егет дип әйтерлек егетләребез –**Әфган сугышы** ветераннары белән җылы очрашу булды.Бу кичәбез ерак Әфган җирендә гомерләре өзелеп, мәңге яшь булып калган солдатлар, ул дәһшәтле көннәрнең шаһиты булып яшәүче исәннәр хакында, кем өчен, ни өчен кан коюлары да аңлашылмаган сугышта һәлак булучылар, бу сугыштан исән-сау кайтучылар турында. Шуңа сөеник, исән кайткан солдатлар арабызда яши. Әфган егетләре... Аларны тикмәгә генә шулай ата-мыйлар. Чөнки алар туган илгә кайткач та әфган егетләре булып калдылар. Безнең туган авылыбыз Наласадан да лачындай егетләргә Әфган җирен, корал тотып утка керергә, иксез-чиксез океаннарны, күкләрне гизәргә туры килде.

Менә алар:
Халиуллин Рөстәм Нурзада улы
Шаһиев Данил Гаптеләхәт улы
Шаһиев Наил Габдрахман улы
Галиуллин Фәрит Әхмәт улы
Гайфуллин Илсур Әхмәдулла улы

Әфган егетләре өчен оештырылган кичәбез матур шигырьләр, җырлар,дәртле биюләр белән үрелеп бар-ды.Ветераннарыбыз балаларны үзләренең тормыш юллары, Әфган җирлегендә хезмәт иткән чорда бул-ган вакыйгалар белән таныштырдылар, истәлекле фотолар белән бүлештеләр.Балаларга матур теләклр теләделәр, тәмле күчтәнәчләр тапшырдылар.

Без дә үз чиратыбызда Әфган ветераннарыбызга олы рәхмәтебезне белдерәбез.Аларга сәламәтлек, озын гомер, тигезлек,балаларының, оныкларының игелеген күреп, бәхеттә, шатлыкта яшәүләрен телибез. Илләребез тыныч,имин булсын.

## «Ватанны саклаучылар көне белән!»

Үз көчендә калсын , үзгәрмәсен
Борынгыдан калган бер өмет.
Ил агасы булып , әти булып,
Горур булып калсын ир-егет.

Безнең балалар бакчасы **23 нче февраль - Ватанны саклаучылар** көне уңаеннан бәйрәм чарасы уздырды . Ватанны саклаучылар көне балаларда патриотизм, сугышчыларга хөрмәт, Ватаныбызның иң яхшы традицияләренә карата бер-берeңне хөрмәт итү хисе тәрбияли. Балалар әтиләренә матур җырларын, сәнгатьле шигырьләрен, дәртле биюләрен бүләк итте. Хөрмәтле әтиләр! Сезнең барыгызны да Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз. Эшегездә, тормышыгызда зур уңышлар , гаилә иминлеге һәм сәламәтлек телибез. «Йөрәктән чыккан сүз йөрәккә җитә» диләр. Киләчәктә энеләр белән бер-берегезнең күңел яктылыгын, җан җылысын тоеп, тынычлыкта, муллыкта яшәгез. Көчле иңнәр күләгәсендә без үзебезне һәрвакыт ныклы терәкле бәхетле кешеләр итеп тоярбыз.











**Ватанны саклаучы әтиләребез турында стенд булдырылды**




**Әти-әниләр ярдәме белән оештырылган «Хәрби кул эшләре» күргәзмәсе**




**«Кышкы уеннар»**

Кыш айлары балаларга уеннар уйнап чыныгып үсәргә яхшы мөмкинлек бирә. Кышкы уеннар балаларның физик һәм акыл сәламәтлеген саклау, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш бирү,спорт яратырга кызыксынучанлыкны, мөстәкыйльлекне, ихтыяр көче, сабырлык, кыюлык сыйфатлары тәрбияләү, балаларның үзләренә хас сыйфатлар булдыру омтылышын формалаштыруны дәвам итү, күңелебезне матур уйлар, сүзләр белән баету, көндәлек тормышта уен вакытында башкаларга каратаягымлы мөгаләмә булдыру максатларын үтәргә ярдәм итә. Кышкы уеннар күп төрле.Балаларыбыз чана, чаңгы шуарга, тимер аякта йөрергә, кар бабай ясарга, кар атыш уйнарга бик яраталар.

Чанада да шуабыз,

Чаңгыда да шуабыз.

Тимераякта очабыз,

Чыжлап тора шома боз.

Балалар, әти-әниләре белән берлектә, үзләренең яраткан уеннарын кәгазь битләренә төшерделәр. Бакчабызда балаларның матур рәсемнәреннән “Кышкы уеннар” исеме астында рәсем күргәзмәсе оештырылды.
















***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Хөсәенова Р.Н., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары****: Гафурова Р.А., Шагиева А.К., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР, Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*